СОВЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 сентябрь 2021 ел** Болгар ш. **№12-6**

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Спас муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибен раслау турында»ТР Спас муниципаль районы Советының 2019 елның 29 июлендәге 40-9 номерлы карары нигезендә, "Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрне тапшыру (кабул итү) турында", Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру:

- җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү;

- рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешүләр төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны закон белән билгеләнгән вакытта Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Спас муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе Ф. В. Мөхәммәтов